СОВЕТ ОМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru


Решение — Карар

“18” сентябрь 2019 г. — № 1-49

## Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Югары Сикәнәс авылы, Совет урамы, Сикәнәс авылы, Елга арты урамы, юлларына вак таш җәю, су үткәрү торбалары сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Березовский поселогында, Омар Пүчинкәсе авылда суэтем башнясын коймалау (материал сатып алу, килешү буенча эшләр башкару).

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башлыгы И.Г.Хәсәнҗановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе /И.Г.Хәсәнҗанов /